**Гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү**

2026 елның 27 мартыннан 2026 елның 20 апреленә кадәр җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итәбез.

Гавами тыңлаулар түбәндәге проектлар буенча билгеләнә:

- Шәхси торак йортлар (Ж1) төзү зонасында «склад» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Шигали авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Шигали авыл җирлеге, Иске Шигали ав., Новоселов ур. адресы буенча урнашкан кадастор номеры 16:33:180102:2344 булган, 2122 кв. м мәйданлы җир кишәрлеген шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты

Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә:

Гавами тыңлауларны үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә – 2026 елның 15 апрелендә 11.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Шигали авыл җирлеге, Иске Шигали авылы, Центральная урамы, 45 йорт (алга таба - Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы).

Проект экспозициясен Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча оештырырга: https://pestreci.tatarstan.ru/zhizn-poseleniya-6828329.htm «Проектлар экспозициясе» бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында, адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шигали авыл җирлеге, Иске Шигали авылы, Центральная урамы, 45 йорт.

Экспозиция һәм гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыруның бөтен чоры дәвамында гавами тыңлауларда катнашучылар проектларга кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- язма рәвештә яки электрон документ формасында гавами тыңлауларны оештыручы адресына, адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Иске Шигали авылы, Центральная урамы, 45 йорт, e-mail: shig.pes@tatar.ru;
- проектлар экспозициясен карап чыгучыларны исәпкә алу китабында (журналында) язу аша, адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шигали авылы, Центральная урамы, 45 йорт;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәргәндә язма яки телдән формада.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, мондый тәкъдим яки искәрмәнең төгәл формулировкасы белән бәян ителергә тиеш.

Гавами тыңлауларда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында мәгълүмат бирәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), туган көне, яшәү урыны адресы (теркәлү) – физик затлар өчен; исеме, төп теркәү номеры, урнашу урыны һәм адресы – юридик затлар өчен) мондый мәгълүматларны раслаучы документлар кушымтасы белән.

Тиешле җир кишәрлекләренең һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының һәм (яки) күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре булып торучы гавами тыңлауларда катнашучылар шулай ук мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән

капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар һәм мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга аларның хокукларын билгели яки раслый торган башка документлар тапшыралар.

Тәкъдимнәр яки искәрмәләр керткәндә, гавами тыңлауларда катнашучылар «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гавами тыңлауларны оештыручыга үзләренең катгый ризалыгын бирәләр.

Әлеге белдерүне «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең рәсми сайтында (https://pestreci.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Хәбибуллин